| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 17.03.2017 | Казан ш. | № 8-1/соц |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарлары үз көчләрен югалтуны тану турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге каралары үз көчләрен югалткан дип таныргa:

«Балалар өчен туклану ризыклары (азык-төлек концентрантларын да кертеп) бәяләренә кумәртәләп сату буенча чик дәрәҗә һәм ваклап сату буенча чик дәрәҗә өстәмә сәүдә бәяләрен билгеләү хакында» 2011 елның 29 июлендәге № 8-13/соц;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Балалар өчен туклану ризыклары (азык-төлек концентрантларын да кертеп) бәяләренә кумәртәләп сату буенча чик дәрәҗә һәм ваклап сату буенча чик дәрәҗә өстәмә сәүдә бәяләрен билгеләү хакында» 2011 елның 29 июлендәге № 8-13/соц карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2011 елның 19 августындагы № 8-16/соц.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов